Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы
«Апаз балалар бакчасы » муниципаль бюджет
мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

5 сан
март 2025



# ЧИШМӘ БАШЫ

Бакчабызның бүгенгесен яктыртучы мәгълүмати электрон газетасы

Газетаның сәхифәсе;

*8- март бәйәме.
* Әниләр турында табышмаклар.
* Әниләр бездә кунакта.
* Нәүрүз бәйрәме.

Баш мөхәррир- тәрбияче : Нигъмәтҗанова Лилия Гаптеләхәт кызы.

Мөхәррир урынбасары - бакча мөдире :Зайнуллина Индира Тәлгать кызы

# 8 –март бәйрәме

Язнын иң беренче бәйрәме, ин матур, ин изге бәйрәме 8 март- халыкара хатын –кызлар бәйрәме, әниләр бәйрәме. Бу бәйрәмне бөтен дөньяда зурлап билгеләп үтәләр.Карагыз күктә ничек кояш колә, табигать уяна, күгәрченнәр горләшә.

- Әни! Күпме наз, күпме җылылык бар бу сүздә. Әниләр, ягымлы әниләр, мэрхәмәтле безнең әниләр , дип җырларда җырлыйлар. Ә безнең балалар күнеленә 8-март Әниләр бәйрәме буларак кереп калган. Балалар аны шулай дип атыйлар да. Балалар бакчасында бу бәйрәмне бик зурлап, бик яратып үткәрәләр. Балалар бу бәйрәмне бик көтеп алалар, аңа бик тырышып әзерләнәләр.Җырлар җырлыйлар, шигырьләр өйрәнәләр, матур биюләр бииләр.
- Кояш көлә, мин елмаям,
- Сигезенче март бүген.
- Бүген әниләр бәйрәме,
- Шуңа күнелем шат минем.

# Әниләр турында мәкальләр

- Әнкәм йорты – алтын бишек.
- Яктылык -кояш янында,
-Яхшылык – әни янында.
-Әти-әни чын дустым,
дус ишләрем юлдашым.
- Өйнең яме әни белән.
- Әткәй - шикәр, әнкәй – бал.
- Әни суккан авыртмый.
-Ана шәфкать диңгезе.
-Дөньяда иң йомшак нәрсә – әнкәй кулы.
Тән биргән дә ана,
Сөт биргән дә ана,
Тел биргәндә ана,
Кой биргәндә ана.







# *Әниләребез бездә кунакта.*

8 - март бәйрәме белән барлык әниләрне, әбиләрне, апайларны котлыйбыз! Әни кеше- гаилә учагын саклаучы, җылылык тудыручы. Ә бүген алар бәйрәмебезнең кадерле кунаклары. Ә бүгенге бәйрәмдә әниләребез, әбиләребез балаларының җырларын, биюләрен шигырьләрен тынладылар. Балалар үз куллары белән ясаган бүләкләрен тапшырдылар.




Науруз


НӘҮРҮЗ


Хуш киләс
Нәүрүз!

Нәүрүз – фарсыча “Яна көн” дигәнне аңлата. Ул бик борынгыдан килгән - Яна елны каршылау бәйрәме булган. Ул көн белән төн тигезләшкән чорга 21-22 мартка туры килгән. Шулай ук бу бәйрәм безнең төбәкләрдә, язны каршылап, язгы чәчү эшләре алдыннан үткәрелә торган булган. Нәүрүз бәйрәме атна –ун көнгә сузылган. Бу бәйрәмендә йорттан-йортка кереп Нәүрүз әйтеп йөрү гадәте булган. Нәүрүз такмагын әйтеп хуҗаларга бәхет, унышлар теләп йөргәннәр. Салкын кышлар бетеп килүенә шатлану, авыл халкының куңелен күтәрү өчен җырлар чыгарылган.

Ач ишеген, керәбез,
Нәүрүз әйтә киләбез,
Хәер - дога кылабыз.
Аш- сый көтеп торабыз,
Нәүрүз мөбарәкбад!

Нәүрүз такмаклары төрлелеге белән аерылып торган. Кыскасы тапкырлык чишмәсе шиңмәгән, кипмәгән.